ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫШЛАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ КШКЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Кшклово. Тел. 3-43-45

КАРАР

1 ноябрь 2022 ел № 4

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар чыгарам:**

1. 2022 елның 16 ноябренә 13.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Кышлау авылы Совет урамы 4 нче йорттан 42 нче йортка кадәр, Тукай урамы 1 нче йорттан 37 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен халык җыенның беренче этабын билгеләргә.
2. 2022 елның 17 ноябренә 13.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Кышлау авылы Татарстан урамы 1 нче йорттан 43 нче йортка кадәр, Чапаев урамы 2 нче йорттан 32 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен халык җыенның икенче этабын билгеләргә.
3. Билгеләргә:
   - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитеты;
   - гражданнар җыенынын беренче этабын үткәрү вакыты – 16 ноябрь 2022 ел 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр;
   - гражданнар җыенынын икенче этабын үткәрү вакыты – 17 ноябрь 2022 ел 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр
   - халык җыенының беренче һәм икенче этабын үткәрү урыны – Кышлау авылы, Татарстан урамы, 7 нче йорт, Кышлау авыл мәдәният йорты залы;
4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:
   - 2022 елның 03 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу

хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Кышлау авылы, Татарстан урамы, 7 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Кышлау торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Кышлау торак пункты халкына гражданнар җыены турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

5. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Кышлау авылы территориясен чистарту (үлән чабу);
2) урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү;
3) урамга яктырткычлар сатып алу;
4) Кышлау авылы зираты юлын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу (килешү буенча хезмәт хакы түләү).

"РИЗА" "КАРШЫ"

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб–адресы, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Кышлау авылы, Татарстан урамы 7 нче йорт адресы буенча Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитеты стендына урнаштырырга.
7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы: А.Х.Кашшапов

Совет Кышлауского сельского поселения
Кышлау авыл җирлеге Советы